**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуган авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татар Шуган авылы №118 13 ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 120 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына (2015 елның 14 август 149 номерлы, 2015 елның 29 октябрендэге 12 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 94 номерлы карарлары басмасында) үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 399 маддәсенең 2 бүлегенә һәм 406 маддәсенең 1 бүлегенә туры китереп,

Татар Шуган авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 120 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына (2015 елның 14 августтагы 149 номерлы, 2018 елның 24 апрелендэ 94номерлы карарлары басмасында), түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1.1. 2 нче бүлектә:

а) 2 бүлекчәне түбәндәге эчтәлектәге 4 нче абзац белән тулыландырырга: “квартираның өлеше”;

б) 3 нче бүлекчәне түбәндәге эчтәлектәге 5 нче абзаң белән тулыландырырга: “торак йортларның өлешләре”.

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыккан коннән бер ай узгач, үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затларның милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә: http://aznakayevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йокләргә.

Утырыш рәисе Мияссарова Г.З.